# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“23” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2019 елның 23 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- Кышлау авылы Чапаев урамына 500 метр арадан чишмә суын китерү;
- торбалар сатып алу һәм салу, насос сатып алу.

2) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Кышлау авылы территориясен чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 260 (ике йөз алтмыш) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 192 (йөз туксан ике) кеше, бу 73,84 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 192 (йөз туксан ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2020 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- Кышлау авылы Чапаев урамына 500 метр арадан чишмә суын китерү;
- торбалар сатып алу һәм салу, насос сатып алу.

2) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Кышлау авылы территориясен чистарту.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.